КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 сентябрь г.Казань № 746

Т«атарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 декабрь, 1637 нче карары белән расланган 2024 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2023 ел, 18 декабрь, 1637 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 31 гыйнвар, 49 нчы, 2024 ел, 19 июнь, 440 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2024 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында цемент терминалы төзү («Ресурс-М» ҖЧҖ, Тукай муниципаль районы).»;

1.13 пунктның 20 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20) «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә «Әгерҗе» сәнәгать паркын төзү («Унипарк» ҖЧҖ, Әгерҗе муниципаль районы);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин